Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы
Әлмәт шәһәр Советы
КАРАРЫ

22 июль 2021 ел №41

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәр Советының 2016 елның 10 августындагы 42 номерлы «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәре җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәрләренә премия бирү һәм башка өстәмә түләүләр турында нигезләмә хакында»гы карарына үзгәрешләр кертү турында

Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәре муниципаль хезмәткәрләре эшчәнлеген стимуллаштыру тәртибен камилләштерү максатларында

Әлмәт шәһәр Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәр Советының 2016 елның 10 августындагы 42 номерлы «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәре җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәрләренә премия бирү һәм башка өстәмә түләүләр турында нигезләмә хакында»гы карарына (Әлмәт шәһәр Советының 2016 елның 6 октябрендәге 48 нче номерлы, 2016 елның 28 декабрендәге 61 нче номерлы, 2018 елның 31 маендагы 121 нче номерлы, 2019 елның 28 августындагы 167 нче номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

- карарга 3 нче кушымтада:

а) 2 пунктка түбәндәге эчтәлекле 2.3 пунктча өстәргә:

«2.3. Озак вакытлы авыру һәм муниципаль хезмәткәрләрнең дәвалануы белән бәйле авыр тормыш ситуациясе килеп чыккан очракларда, тотылган чыгымнарны раслый торган медицина оешмаларыннан документлар бирелеп тиешле шартлар үтәлгәндә (хезмәткә сәләтсезлек кәгазе, эпикриз, медицина хезмәте күрсәтү турында шартнамәләр күчермәләре, касса чеклары, квитанцияләр).»;

б) түбәндәге эчтәлекле 11 пункт өстәргә:

«11. Муниципаль хезмәткәрнең озак авыруы һәм аның дәвалануы белән бәйле рәвештә бирелүче матди ярдәм бер айлык акча күләмендә түләнә.».

2. Район башкарма комитетының хокук идарәсенә (Ханнанова Ә Б.) әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы»нда (PRAVO.TARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайты «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны шәһәр Советының бюджет - финанс мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә (Мусин Р.Ф.).

Шәһәр Башлыгы Т.Д. Нагуманов